**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘТНӘ МУНИЦИАЛЬ РАЙОНЫ
КҮЛЛЕ-КИМЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
КУЛЛЕ-КИМИНСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ АТНИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

422742 Республика Татарстан Атнинский район с. Кулле-Кими ул.Кирова 1А Тел. 3-53-40

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«18» июня 2025 ел № 6

**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күлле-Киме авыл җирлеге башкарма комитетының 2017 елның 28 февралендәге 6 номерлы «Әтнә муниципаль районы Күлле-Киме авыл җирлегенең муниципаль органнары, муниципаль казна һәм бюджет учреждениеләре тарафыннан аерым төр товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алуга таләпләрне (шул исәптән товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрнең чик бәяләрен дә) һәм Әтнә муниципаль районы Күлле-Киме авыл җирлегенең муниципаль органнары, муниципаль казна учреждениеләре функцияләрен тәэмин итүгә норматив чыгымнарны билгеләү кагыйдәләрен раслау турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында**

2019 елның 1 маендагы 71-ФЗ номерлы "Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында" Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында" Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2019 елның 20 июлендәге 946 номерлы "Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында" карары, Татарстан Республикасы Әтнә районы прокуратурасының 2025 елның 28 мартындагы 02-08-02-2025/Прдп182-25 номерлы протесты нигезендә, Күлле-Киме авыл җирлеге башкарма комитеты карар бирә:

1. Әтнә муниципаль районы Күлле-Киме авыл җирлеге башкарма комитетының 2017 елның 28 февралендәге 6 номерлы «Әтнә муниципаль районы Күлле-Киме авыл җирлегенең муниципаль органнары, муниципаль казна һәм бюджет учреждениеләре тарафыннан аерым төр товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алуга таләпләрне (шул исәптән товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрнең чик бәяләрен дә) һәм Әтнә муниципаль районы Күлле-Киме авыл җирлегенең муниципаль органнары, муниципаль казна учреждениеләре функцияләрен тәэмин итүгә норматив чыгымнарны билгеләү кагыйдәләрен раслау турында» карарының 2 нче кушымтасына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. Күлле-Киме авыл җирлегенең муниципаль органнары, муниципаль казна учреждениеләре функцияләрен тәэмин итүгә норматив чыгымнарны билгеләү кагыйдәләрен (2 нче кушымта) кушымта нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында "Интернет" мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча һәм Әтнә муниципаль районының рәсми сайтында http://atnya.tatarstan.ru адресы буенча бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Күлле-Киме авыл җирлеге башлыгы Гараев Х.Х.

**Күлле-Киме авыл җирлеге**
**башкарма комитетының**
2017 елның 28 февралендәге 6
номерлы карарына 2 нче кушымта
18.06.2025 ел, 6 номерлы
карар редакциясендә

**Әтнә муниципаль районы Күлле-Киме авыл җирлегенең муниципаль органнары, муниципаль казна учреждениеләре функцияләрен тәэмин итүгә норматив чыгымнарны билгеләү кагыйдәләре**

Әтнә муниципаль районы Күлле-Киме авыл җирлегенең муниципаль органнары, муниципаль казна учреждениеләре функцияләрен тәэмин итүгә норматив чыгымнарны билгеләгәндә, "Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2014 елның 13 октябрендәге 1047 номерлы карары (Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2019 елның 20 июлендәге 946 номерлы карары редакциясендә) белән расланган Дәүләт органнары, дәүләт бюджеттан тыш фондлары белән идарә итү органнары һәм муниципаль органнар, Россия Федерациясе Бюджет кодексы нигезендә билгеләнгән иң әһәмиятле фән, мәгариф, мәдәният һәм сәламәтлек саклау учреждениеләре, шул исәптән тиешле территориаль органнар һәм буйсынучы казна учреждениеләре, шулай ук "Росатом" атом энергиясе буенча дәүләт корпорациясе, "Роскосмос" космик эшчәнлек буенча дәүләт корпорациясе һәм аларга буйсынучы оешмалар функцияләрен тәэмин итүгә норматив чыгымнарны билгеләүнең гомуми кагыйдәләре кулланыла.